**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 9 сентябрендәге ПУ-365 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты актларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 10 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 8 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты указлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларының үз көчен югалткан нигезләмәләре исемлегенең 5 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2019 елның 1 февралендәге ПУ-50 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 3 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану

турында» 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 11 пункты.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 19 май
№ 313

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның « 19 » маендагы
313 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте (алга таба – Матбугат хезмәте) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Матбугат хезмәте Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы мәгълүмат сәясәте өлкәсендәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны, Татарстан Республикасы Рәисенең массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында төзелде. Матбугат хезмәте Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мәгълүмат сәясәте өлкәсендәге эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлеге белән бәйле аерым бурычларны һәм функцияләрне тормышка ашыра.

3. Матбугат хезмәте үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына һәм шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Матбугат хезмәте турыдан-туры Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

Матбугат хезмәтенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мәгълүмат сәясәте өлкәсендәге эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлеге белән бәйле эшчәнлеге мәсьәләләренә Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе җитәкчелек итә.

5. Матбугат хезмәте турында нигезләмә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

## II. Матбугат хезмәтенең төп бурычлары

6. Матбугат хезмәтенең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге турында, Татарстан Республикасы Рәисенең басылып чыга торган актлары, Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының белдерүләре, чыгышлары, очрашулары һәм алар катнашында башка чаралар турында мәгълүмат бирү;

Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына Татарстан Республикасының мәгълүмат сәясәте, Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлеге мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры кушуы буенча әлеге тәкъдимнәрне гамәлгә ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлеген оештыру һәм тәэмин итү;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеген яктырту.

## III. Матбугат хезмәтенең төп функцияләре

7. Матбугат хезмәтенең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисенең Мәгълүмат-аналитика идарәсе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең башка структур бүлекчәләре белән берлектә массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы аерым коллегиаль органнар эшчәнлеген яктырту турында Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры катнашындагы чараларны мәгълүмати тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министрының интервьюларын, матбугат конференцияләрен, башка чыгышларын оештыру, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры катнашында чараларны яктырту өчен массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен чакыру;

массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү;

массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары структур бүлекчәләре (вазыйфаи затларының) Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеген яктырту буенча эшен координацияләү;

Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының дәүләт, рәсми һәм башка визитларын, рәсми очрашуларын, әңгәмәләрен, эшлекле сәфәрләрен әзерләү һәм уздыруда, шулай ук алар катнашында Россия Федерациясе территориясендә һәм чит илләрдә уздырылган чараларда аларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатларында катнашу;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында актуаль мәсьәләләр буенча атна саен брифинглар оештыру һәм үткәрү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе өчен Матбугат хезмәте компетенциясенә караган мәсьәлә буенча массакүләм мәгълүмат чараларындагы, «Интернет» челтәрендәге мәкаләләргә һәм хәбәрләргә күзәтүләр, шулай ук белешмәләр һәм аналитик материаллар, шул исәптән аерым актуаль темалар буенча да, әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры катнашындагы чараларны перспектив һәм оператив планлаштыруда катнашу;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеген объектив һәм һәрьяклап яктырту максатларында республика, федераль һәм чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары, шулай ук аерым журналистлар белән хезмәттәшлек итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының башка структур бүлекчәләре белән берлектә массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге турында төрле материаллар әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе рәсми сайтларына булышлык күрсәтү буенча эшне координацияләү һәм контрольдә тоту, «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Татарстан Республикасы рәсми порталы) техник операторы белән хезмәттәшлек итү;

Татарстан Республикасы рәсми порталында һәм аның составына керә торган Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе рәсми сайтларында Матбугат хезмәте компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмат урнаштыру;

Матбугат хезмәте компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыклары, Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәләре проектлары әзерләүдә катнашу, шулай ук аларны тормышка ашыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты структур бүлекчәләренә консультатив ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы матбугатын, массакүләм мәгълүмат чараларын һәм массакүләм коммуникацияләрне үстерүгә зур өлеш керткән затларны бүләкләү һәм аларны дәүләт бүләкләренә тәкъдим итү турында тәкъдимнәр кертү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры исеменнән истәлекле һәм юбилей даталары белән котлау текстлары әзерләүдә катнашу, шулай ук аларны массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру.

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәсе буенча Матбугат хезмәте башка функцияләрне башкара.

## IV. Матбугат хезмәтенең хокуклары

8. Матбугат хезмәте үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле мәгълүмат һәм материалларны соратып алырга;

массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек өчен җаваплы федераль һәм республика башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары структур бүлекчәләре (вазыйфаи затлары), шулай ук Россия, чит ил, төбәк һәм җирле массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән багланышларны сакларга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларында булган мәгълүматлардан файдаланырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килештереп, Матбугат хезмәте эшчәнлегенең аерым юнәлешләрен тормышка ашыру өчен билгеләнгән тәртиптә фәнни оешмалар вәкилләрен, галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә.

## V. Матбугат хезмәтенең хезмәттәшлек итү даирәсе

9. Матбугат хезмәте үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, башка оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр һәм вазыйфаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

10. Матбугат хезмәте хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы.

## VII. Матбугат хезмәте эшчәнлеген оештыру

11. Матбугат хезмәтенең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

12. Матбугат хезмәте эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе боерыгы нигезендә вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте җитәкчесе (алга таба – Матбугат хезмәте җитәкчесе) җитәкчелек итә.

13. Матбугат хезмәте җитәкчесе:

Матбугат хезмәте эшен оештыра, Матбугат хезмәтенә йөкләнгән бурычларның үтәлүенә җаваплы була;

Матбугат хезмәтенең төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

үз компетенциясе чикләрендә документларга кул куя һәм имза сала;

Матбугат хезмәте хезмәткәрләре арасында вазыйфаи бурычларын бүлә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә аларның вазыйфаи регламентларын раслауга бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Матбугат хезмәтенең структурасы, штат саны, Матбугат хезмәте хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую һәм биләгән вазыйфасыннан азат итү турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Матбугат хезмәте хезмәткәрләрен бүләкләү һәм аларны дисциплинар җәзага тарту турындагы тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары уздырган коллегияләр утырышларында, киңәшмәләрдә катнаша,

билгеләнгән тәртиптә коллегия утырышларында һәм киңәшмәләрдә катнашу өчен Матбугат хезмәте вәкилләрен җибәрә.

14. Матбугат хезмәте җитәкчесенең ике урынбасары бар, алар Матбугат хезмәте җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

Матбугат хезмәте җитәкчесе вакытлыча эш урынында булмаган чорда, аның вазыйфаларын Матбугат хезмәте җитәкчесе урынбасарларының берсе яисә Матбугат хезмәтенең башка вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

15. Матбугат хезмәте хезмәткәрләре Матбугат хезмәте җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.